**«РАСЛЫЙМ»**

**Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры**

**________________ Э.Н. Фәттахов**

**"___" ___________ 2015 нче ел**

# ТАТАР ТЕЛЕ

## Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының IX сыйныф укучыларына 2015 нче елда татар теленнән бердәм республика тесты уздыру өчен куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан әзерләнде

## Татар телендә гомуми белем бирү мәктәпләренең IX сыйныф укучыларына татар теленнән 2015 нче елда бердәм республика тестын уздыру өчен куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы

Татар теленнән төп гомуми белем бирү программаларын үзләштергән чыгарылыш сыйныф укучыларына 2015 нче елда бердәм республика тестын уздыру өчен әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы (алга таба – кодификатор) – бердәм республика тестын уздыру өчен үрнәк материалларны эшләү тәртибен билгели торган мөһим документларның берсе.

Ул "Татар телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теленнән программа"га (5-11 нче сыйныфлар. – Казан: Мәгариф, 2011) һәм "Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программага (5 – 9 нчы сыйныфлар. – Казан, 2014, http://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_263448.docx) нигезләнеп төзелде.

Әлеге документ төп мәктәп курсы буенча татар теленнән үрнәк материалларны эшләү өчен нигез булып тора, өйрәнү материалы гомумиләштерү һәм системалаштыру принцибына корылган.

Калын курсив хәрефләр белән эчтәлеге киңрәк булган бүлекләр язылды, алар кечкенәрәк блокларга бүлеп бирелде. Кодификаторның һәр элементы уку эчтәлегенең эреләндерелгән дидактик берәмлеген тәшкил итә, шуңа күрә анда бер тема буенча берничә бирем булырга мөмкин. Икенче баганада тикшерү биремнәре төзелә торган элементның коды күрсәтелгән.

### 1 нче бүлек. Төп мәктәп курсы буенча татар теленнән бердәм республика тесты барышында тикшерелә торган эчтәлек элементлары исемлеге

Төп мәктәп курсы буенча татар теленнән бердәм республика тесты барышында тикшерелә торган эчтәлек элементлары исемлеге[1] татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программага (5 – 9 нчы сыйныфлар) (Казан, 2014. Төз.- авторлар: Галиуллина Г.Р., Шәкүрова М.М., http://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_263448.docx ) нигезләнеп төзелде.

| Бүлек коды | Тикшерелә торган элемент коды | Тикшерелә торган материалның эчтәлеге |
|---|---|---|
| ***1*** | | ***Фонетика, орфоэпия*** |
| | 1.1 | Аваз һәм хәреф |

| | | |
|---|---|---|
| | 1.2 | Сузык авазларның рәт һәм ирен гармониясе |
| | 1.3 | Тартык авазларның уңай һәм кире ассимиляциясе |
| | 1.4 | Фонетик анализ |
| ***2*** | | ***Лексикология һәм фразеология*** |
| | 2.1 | Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәсе |
| | 2.2 | Бер һәм күп мәгънәле сүзләр |
| | 2.3 | Синонимнар. Антонимнар. Омонимнар. |
| | 2.4 | Фразеологик әйтелмәләр |
| | 2.5 | Лексик анализ |
| ***3*** | | ***Сүз ясалышы*** |
| | 3.1 | Сүзләрнең мәгънәле кисәкләре |
| | 3.2 | Кушымчаларның төрләре |
| | 3.3 | Сүзләрнең ясалышы буенча төрләре |
| | 3.4 | Сүзләрнең төзелешен һәм ясалышын тикшерү |
| ***4*** | | ***Грамматика. Морфология*** |
| | 4.1 | Мөстәкыйль сүз төркемнәре |
| | 4.2 | Модаль сүз төркемнәре |
| | 4.3 | Хәбәрлек сүзләр |
| | 4.4 | Бәйләгеч сүз төркемнәре |
| | 4.5 | Морфологик анализ |
| ***5*** | | ***Грамматика. Синтаксис*** |
| | 5.1 | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше һәм аның төрләре |
| | 5.2 | Сүзтезмә |
| | 5.3 | Гади җөмләләрнең төрләре. |
| | 5.4 | Җөмләнең грамматик кисәкләре: баш кисәкләр |
| | 5.5 | Җөмләнең иярчен кисәкләре |
| | 5.6 | Җөмләнең модаль кисәкләре |
| | 5.7 | Җөмләнең тиңдәш кисәкләре, алар янында гомумиләштерүче сүзләр |
| | 5.8 | Гади җөмләләргә синтаксис анализ |
| | 5.9 | Тезмә кушма җөмлә һәм аның төрләре |
| | 5.10 | Иярченле кушма җөмлә һәм аның төрләре |
| | 5.11 | Күп тезмәле һәм күп иярченле катлаулы кушма җөмлә |
| | 5.12 | Катнаш кушма җөмлә |
| | 5.13 | Кушма җөмләләргә синтаксик анализ |

| | | |
|---|---|---|
| *6* | | ***Графика һәм орфография*** |
| | 6.1 | Сузык авазларны белдергән хәрефләрнең дөрес язылышы |
| | 6.2 | Тартык авазларны белдергән хәрефләрнең дөрес язылышы |
| | 6.3 | ъ һәм ь хәрефләренең дөрес язылышы |
| *7* | | ***Пунктуация*** |
| | 7.1 | Ия белән хәбәр арасында тыныш билгесе |
| | 7.2 | Гади җөмләдә (тиңдәш кисәкләр, модаль кисәкләр, аерымланган хәлләр) янында тыныш билгеләре |
| | 7.3 | Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә, аналитик һәм синтетик иярчен җөмләле, күп иярченле һәм катнаш кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре |
| ***8*** | | ***Сөйләм*** |
| | 8.1 | Сөйләм берәмлеге буларак текст |
| | 8.2 | Сөйләм төрләре |
| | 8.3 | Сөйләмгә куела торган таләпләр |
| | 8.4 | Төрле стиль һәм жанрга караган текстларны тикшерү |
| | 8.5 | Стильләрнең лексик-грамматик үзенчәлекләре |
| | 8.6 | Төрле стильдәге һәм сөйләм төрендәге текстлар төзү |
| **9** | | Тел нормалары |
| | ***9.1*** | Орфоэпик нормалар |
| | ***9.2*** | Лексик нормалар |
| | ***9.3*** | Грамматик нормалар (морфологик нормалар) |
| | ***9.4*** | Грамматик нормалар (синтаксик нормалар) |
| **10** | | Татар сөйләменең матурлыгы |
| | ***10.1*** | Татар әдәби теленең байлыгы һәм тәэсирле булуы |
| | ***10.2*** | Лексика һәм фразеологиянең тәэсирлелек чаралары |
| | | Төрле стильдәге һәм жанрдагы текстларны тикшерү |

## 2 нче бүлек. Төп мәктәп курсы буенча татар теленнән бердәм республика тесты барышында тикшерелә торган әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр исемлеге

Программа беренче чиратта укучыларның сөйләм һәм акыл (интеллектуаль) эшчәнлеге үстерүне куздә тота.

Бу бүлектә укучыларның татар теленнән төп мәктәп курсына куела торган таләпләр китерелә.

| **Таләпнең коды** | | **Бердәм республика тесты барышында тикшерелә торган күнекмәләр** |
|---|---|---|
| *1* | | ***Анализ төрләре*** |
| | 1.1 | Тел берәмлекләрен табып, аларны төрле (фонетик, лексик, сүз төзелеше, морфологик, синтаксик) яктан тикшерү |
| | 1.2 | Текстның (өзекнең) темасын, төп фикерен билгеләү |
| | 1.3 | Телдән һәм язма сөйләмне аеру, төрле стиль һәм жанрга караган текстларны тикшерү |
| *2* | | ***Тыңлап аңлау һәм уку*** |
| | 2.1 | Телдән һәм язма сөйләмне тиешенчә аңлау |
| | 2.2 | Төрле стиль һәм жанрдагы текстларны уку |
| | 2.3 | Өйрәнү, танышу, карап чыгу характерындагы уку төрләренә ия булу |
| | 2.4 | Төрле чыганаклардан (белешмәлек һәм сүзлекләрдән) кирәкле мәгълүматны таба белү |
| *3* | | ***Язу*** |
| | 3.1 | Текстның планын төзү, эчтәлеген сөйләү, изложение язу |
| | 3.2 | Төрле стиль һәм жанрдагы текстлар (бәяләмә, чыгыш, хат, расписка, гариза һ.б.ш.) язу |
| | 3.3 | Темага, максатка һәм аралашу ситуциясенә ярашлы тел чараларын сайлап, урынлы куллана белү |
| | 3.4 | Монолог һәм диалогның төрле төрләреннән файдалану |

| | | |
|---|---|---|
| | 3.5 | Телдән һәм язма сөйләмдә үз фикереңне иркен рәвештә дөрес итеп, темага туры китереп, эзлекле һәм бәйләнешле итеп белдерү |
| | 3.6 | Сөйләмдә хәзерге татар әдәби теленең орфоэпик, лексик, һәм грамматик нормаларын үтәү |
| | 3.7 | Язуда орфография һәм пунктуациянең төп кагыйдәләрен саклау |
| | 3.8 | Татар сөйләм әдәбе нормаларын үтәү |
| | 3.9 | Үз сөйләмеңнең, төзегән текстларның дөреслеген тикшерү, андагы грамматик һәм сөйләм хаталарын табып төзәтү |